БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» 08 2018 г. № 284

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне 2015 -2020 елларга гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш системасын камилләштерү максатыннан һәм Россия Федерациясе Президентының «2018-2020 елларда Коррупциягә каршы көрәш милли планы» турындагы 2018 елгы 29 июнендәге 378 нче номерлы Указынның үтәлешен тәэмин итү ягыннан Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Балтач районы башкарма комитетының 13.11.2014 елгы 347 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне 2015-2020 елларга гамәлгә ашыру» турындагы муниципаль программасына (18.12.2015 №481, 23.05.2016 №136, 15.12.2017 №274 нчы үзгәрешләр белән) кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә (алга таба - муниципаль программа).
2. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштырырга.
3. Әлеге карар кул куйган көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.И.Шакиров